РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

423303, Азнакаевский район, с. Агерзе, ул.Г.Ахметовой, д.14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты

423303, Азнакай районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «16» март 2020 ел. № 7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 09 январендә 2 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2019 елның 23 декабрендә «Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү» мәсьәләсе буенча видеоконференция режимында республика киңәшмәсе нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләре исемлегенең 4.7 пунктын үтәү йөзеннән,
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 09 январендә 2 номерлы «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү буенча муниципаль программа турында» карары белән расланган, 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль программасына «Чаралар исемлеген» түбәндәге эчтәлекле 2 бүлегендәге 2.3 пунктын яңа редакциядә бәян итеп:

| 2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати, консультация һәм мөлкәт ярдәме күрсәтү | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3 | Озак вакытка исәпләнгән нигездә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына өченче затлар хокукларыннан азат ителгән муниципаль мөлкәтне бирү (статья 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы редакциясендә) | 2020-2022 еллар | Финанслау таләп ителми | - | - | - | - | Авылҗирлегеб ашкарма комитеты |

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис: Н.Н.Хәсәнов